**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САВАЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Центральная, д.11, с. Савалеево, Заинский район, 423537

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӘВӘЛӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Үзәк урамы, 11 нче йорт, Сәвәләй авылы, Зәй районы, 423537

Телефон/факс 62-3-47. Электронный адрес: Sav.Zai@tatar.ru,
сайт: http://zainsk.tatarstan.ru/rus/savaleevskoe.htm


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2019 ел № 23

**«Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында»**

Яңа ел бәйрәмнәре вакытында Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә янгыннар чыгуны һәм аларда кешеләр үлүне кисәтү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законы, «Федераль дәүләт янгын күзәтчелеге турында» 2012 елның 12 апрелендәге 290 номерлы РФ Хөкүмәте карары, Зәй муниципаль районы «Сәвәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 47 статьясы нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2019 елның 15 декабреннән 2020 елның 15 гыйнварына кадәр Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертергә.

2. Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә торак йортлар һәм объектлар янында пиротехник эшләнмәләр куллануны тыярга.

3. Тәкъдим итәргә:

3.1. Сәвәләй авыл җирлегендә яшәүчеләргә һәм кунакларга:

- пиротехник эшләнмәләр кулланганда куркынычсызлык таләпләрен үтәргә.

3.2. Пиротехник эшләнмәләрне саклау һәм сату белән шөгыльләнүче юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә пиротехник эшләнмәләр белән мөрәҗәгать итүгә куела торган янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3.3. Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә урнашкан "Район Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» муниципаль казна учреждениесе, “Район Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе" муниципаль казна учреждениесе, “Район башкарма комитетының мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе, «Район Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчеләренә:

- Яңа ел бәйрәм чараларына әзерлек һәм үткәрү чорында янгын куркынычсызлыгы чаралары комплексын үтәргә;

- Зәй муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге белән Яңа ел бәйрәм чараларын үткәрү урыннарын килештерергә;

- түбән температура вакытында мич һәм электр җиһазларының техник торышына профилактик тикшерүләр үткәрергә, электр челтәрләренең артык йөкләнешенә юл куймаска;

- мичләрдән һәм электр җылыту приборларыннан файдаланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү буенча учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәт күрсәтүче персоналларга инструктажлар оештырырга һәм үткәрергә.

3.4. Шәхси торак йорт хуҗаларына:

- җылыту мичләрен, яктырту челтәрләрен һәм газ җиһазларын тикшерү һәм ремонтлауны үткәрергә;

- электр һәм газ җиһазларының төзексезлеген бетерү өчен әлеге эшчәнлек төрләренә лицензиясе булган махсуслаштырылган оешмаларга мөрәҗәгать итәргә;

- сертификацияләнгән электр җылыту приборларыннан гына файдаланырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **П.С. Уразайкин**

Исп. Л.М.Соколова
62-3-47